ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТЗА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӘЙРӘКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР №12

Бәйрәкә ав. «24» декабрь 2025 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге Советының 2024 елның 27 апрелендәге «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы 10 санлы карарына үзгәреш кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексы, 2025 елның 20 мартындагы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 33-ФЗ санлы Федераль закон, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, 2014 елның 30 октябрендәге «Татарстан Республикасы территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып билгеләү тәртибен куллана башлауның бердәм датасын билгеләү турында»гы 82-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Бәйрәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлек Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге Советының 2024 елның 27 апрелендәге «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы 10 санлы карарына (Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге Советының 2024 елның 16 сентябрендәге 22 санлы, 2024 елның 11 ноябрендәге 25 санлы, 2025 елның 18 ноябрендәге 9 санлы, 2025 елның 1 декабрендәге 10 санлы карарлары редакциясендә) (алга таба - Карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Карарның 2 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) проектлана торган билгеләнеше күпфатирлы йорт булган тәгалләнмәгән төзелеш объектларыннан тыш, һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артыграк булган салым салу объектларына карата 2,5 процент».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми бастырып чыгару юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә (https://pravo.tatarstan.ru Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан 2013 елның 17 декабрендә бирелгән ЭЛ ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык) һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт

хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» бердәм порталын урнаштырырга. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адресы буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән бер ай узгач үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Бәйрәкә авыл җирлеге башлыгы — А.О.Әхмәтшина

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БӘЙРӘКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
СОВЕТ БАЙРЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН